Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы
Бәзәкә авыл җирлеге составына керүче
Татар Тәкәше авылында
ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ

КАРАР

25 ноябрь 2023 ел — № 10

2024 елга гражданнарның үзара салымын кертү турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Татар Тәкәше авылы гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. «2024 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районының Бәзәкә авыл җирлегенең Татар Тәкәше авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I-II төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылар һәм аларга тиңләштерелгәннәрдән, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, ә күп балалы гаиләләрдән 50% ка киметеп 500 сум күләмендә билгеләргә, махсус хәрби операциядә катнашучыларны түләүдән азат итәргә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә

1.Татар Тәкәше авылына юлларны кардан чистарту

2. Татар Тәкәше авылында суүткәргеч торбалар, тоташтыру муфталары сатып алу

3. Татар Тәкәше авылында суүткәргеч торбаларны алыштыру буенча хезмәтләргә түләү.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында «Бәзәкә авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга http://mendeleevsk.tatarstan.ru

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Бәзәкә авыл җирлеге башлыгы — И.И. Кәшәфетдинов